Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Тимәш авыл җирлегенең Тимәшавылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге Тимәшавылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Тимәш авыл җирлеге Тимәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаиләләре, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, ялгыз пенсионерлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: Молодежная урамына вак таш җәю, Школьная урамындагы юлларда чокырлар ремонтлау, Тимәш авылында юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71Д (җирле үзидарә бинасы), Киров урамы, 26 (мәдәният йорты), нефтьүткәргечләр урамы, 20 (Ромашкино РНУ утырышлар залы), Киров урамы, 1А («Ласточка» балалар бакчасы), Лесная урамы, 20, Лесная урамы, 33 адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.
4. Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль
берәмлеге башлыгы Р.М.Сираев